**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РУССКО-ОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422642, с. Русский Ошняк,
ул. Профсоюзная, дом 7а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**РУС ӘШНӘГЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422642, Рус Әшнәге авылы,
Профсоюз урамы, 7а нче йорт,

Тел.: (84361) 24643, факс: (84361) 24643, e-mail: Rosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.06.2019 Рус Әшнәге авылы №5

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 1 номерлы карары белән расланган административ регламентларына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеш кодексына кертелгән үзгәрешләргә туры китерү максатларында Росс Федерациясенең аерым закон актларына территорияне планлаштыру документлары әзерләүне, килештерүне һәм раслау, территорияләрне комплекслы һәм тотрыкл үстерүне тәэмин итү һәм Россия Федерациясе закон актларының аеры нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану өлешендә, Россия Юстиц министрлыгының 2017 елның 6 июнендәге “Җирлекләрнең жирл администрацияләре башлыклары һәм җирлекләрнең җирле үзидарәләренең махсу вәкаләтле вазифаи затлары, муниципаль районнарның җирле администрацияләр башлыклары һәм муниципаль районнарның махсус вәкаләтле вазифаи затлар тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында инструкцияне расла хакында” 97нче номерлы Боерыгына, "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон “Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль тора фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга тора урыннары бирү хокукларын тормышка ашыру турында” 2007 елның 13 июлендә 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы 1 номерлы карар белән расланган үзидарәлек хезмәтләре күрсәтүнең администрати регламентларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1 номерлы кушымтаның 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон чыгаручы яки бүтән норматив хокукый актлар нигезендә зарури документларның, шулай ук муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә тиешле тулы исемлеге | Торак урынына мохтаҗлар сыйфатында гражданнарны исәпкә алу өчен:<br>1) Гариза (кушымта №1);<br>2)Мөрәҗәгать итүче гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының паспортларының яисә шәхесне таныклаучы бүтән документларының күчермәләре;<br>3) Мөрәҗәгать итүче гражданның гаилә составы турындагы документларының күчермәләре;<br>4) Мөрәҗәгать итүче гражданны яисә аның гаилә әгъзаларын торак законнары нигезендә чираттан тыш торак урыны бирүгә хокукы булган гражданнар категориясенә кертергә нигез булырдай документлар:<br>-медицина оешмасыннан медицина белешмәсе – гражданның гаилә составында хроник чирнең авыр формасыннан интегүче булып, аның белән бер фатирда бергә көн итү мөмкинлеге булмаганда, Россия Федерациясенең вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан расланган исемлек буенча;<br>-химая һәм кайгыртучылык органнарыннан химаяче билгеләү турында белешмә – хокуктан файдалануга сәләтсез граждан исеменнән эш итүче химаяче тарафыннан исәпкә алу турында гаризаны имзалау очрагында;<br>-ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар саныннан затларның аларның белем бирү һәм башка учреждениеләрдә, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә, тәрбиягә бала алучы гаиләләрдә, гаилә тибындагы балалар йортларында булулары тәмамланганнан соң, химаячелек (кайгыртучылык) туктатылганда, | ТР ның №31-ЗРТ номерлы Законының 6 маддәсе |

| | | |
|---|---|---|
| | шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү тәгәлләнгәннән яки иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза утәү учреждениеләреннән кайтканнан соң шул статусны раслаучы документлар.<br>Барлык документларны бер үк вакытта төп нөсхәләрен тәкъдим итеп күчермәләрдә бирү киңәш ителә.<br>Үзидарәлек хезмәтен алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче шәхсән Башкарма комитетка мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәлгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь йөрткечләрдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (юлланырга) мөмкин:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аркылы.<br>Гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шулай ук көчәйтелгән югары квалификацияле электрон култамга белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми керү мөмкинлеге булган мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, шул исәптән Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәре һәм дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең Бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |

1.2) 1 номерлы кушымтаның 3.3.2. пунктының 8 абзацын түбәндәге редакциял бәян итәргә:

“гариза тапшырган гражданнарга тәкъдим ителгән документларның исемлеге һәм алу датасын, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслага форма буенча ведомствоара гарызнамәләр буенча алыначак документларны исемлеген күрсәтеп алу турындагы расламаны бирү”;

1.3) 1 номерлы кушымтаның 2.9 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакцияд бәян итәргә:

"дәүләт органы, җирле үзидарә органы, оешманың ведомствоара гарызнамәг җавабы килеп ирешү Татарстан Республикасының 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗР номерлы Законының 6 маддәсе нигезендә гражданнарны торак урынга мохта сыйфатында кабул итү өчен кирәкле документның һәм (яки) мәгълүматны булмавы турында дәлилли, әгәр тиешле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан ү инициативасы буенча тапшырылмаган булса, соратыла торган анды документларның яки мәгълүматның ул орган яисә оешмалар карамагында булмаві тиңдәшле гражданнарның торак урыннарга мохтаҗ сыйфатында исәптә торыр хокукын раслау очракларыннан гайре";

1.4) 2 номерлы кушымтаның 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон чыгаручы яки бүтән норматив хокукый актлар нигезендә зарури документларның, шулай ук муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә тиешле тулы исемлеге | Торак урынына мохтаҗлар сыйфатында гражданнарны исәпкә алу өчен:<br>1) Гариза (кушымта №1);<br>2)Мөрәҗәгать итүче гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының паспортларының яисә шәхесне таныклаучы бүтән документларының күчермәләре;<br>3) Мөрәҗәгать итүче гражданның гаилә составы турындагы документларының күчермәләре;<br>4) Мөрәҗәгать итүче гражданны яисә аның гаилә әгъзаларын торак законнары нигезендә чираттан тыш торак урыны бирүгә хокукы булган гражданнар категориясенә кертергә нигез булырдай документлар:<br>-медицина оешмасыннан медицина белешмәсе – гражданның гаилә составында хроник чирнең авыр формасыннан интегүче булып, аның белән бер фатирда бергә көн итү мөмкинлеге булмаганда, Россия Федерациясенең вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан расланган исемлек буенча;<br>-химая һәм кайгыртучылык органнарыннан химаяче билгеләү турында белешмә – хокуктан файдаланууга сәләтсез граждан исеменнән эш итүче химаяче тарафыннан исәпкә алу турында | ТР ның №31-ЗРТ номерлы Законының 6 маддәсе |

| | | |
|---|---|---|
| | гаризаны имзалау очрагында;<br>-ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар саныннан затларның аларның белем бирү һәм башка учреждениеләрдә, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә, тәрбиягә бала алучы гаиләләрдә, гаилә тибындагы балалар йортларында булулары тәмамланганнан соң, химаячелек (кайгыртучылык) туктатылганда, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү тәгәлләнгәннән яки иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәү учреждениеләреннән кайтканнан соң шул статусны раслаучы документлар.<br>Барлык документларны бер үк вакытта төп нөсхәләрен тәкъдим итеп күчермәләрдә бирү киңәш ителә.<br>Үзидарәлек хезмәтен алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче шәхсән Башкарма комитетка мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәлгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь йөрткечләрдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (юлланырга) мөмкин:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аркылы.<br>Гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шулай ук көчәйтелгән югары квалификацияле электрон култамга белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми керү мөмкинлеге булган мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, шул исәптән Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәре һәм дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм үзидарәлек хезмәтләренең Бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |

1.5) 3 номерлы кушымтаның 1.5 пунктының 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

" планлаштыру структурасы элементы – җирлек, шәһәр округ территориясенең яки муниципаль районның авыллар арасындагы территориясенең бер өлеше (квартал, микрорайон, район һәм башка охшаш элеменлар). Планлаштыру структурасы элементларының төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә".

1.6) 4 номерлы кушымтаның 2.5 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) Күчермәләрнең яисә алардан өземтәләрнең дөреслеген таныклау өчен тәкъдим ителгән күләме бер биттән артып киткән документлар аларны беркетү юлы белән яисә аларның бөтенлегенә шик калдырмый торган башка ысул белән тәэмин ителергә тиеш.

Әгәр документта булган искәртелмәгән төзәтүләр яки башка кимчелекләр документлар тапшырылган максатлар өчен житди, мөһим булмасалар, җирле үзидарәнең урындагы заты андый документны күчермәнең дөреслеген таныклау өчен кабул итәргә хаклы";"

1.7 4 номерлы кушымтаның 2.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр күздә тотылмый.<br>Кире кагу өчен нигезләр:<br>-андый гамәлне кылу Россия Федерациясе законнарына каршы килә;<br>-гамәл башка җирлекнең яисә муниципаль районның җирле үзидарәсенең вазифаи заты тарафыннан яки нотариус тарафыннан кылынырга тиешле (мирас мөлкәтен саклау буенча һәм кирәк булган очракта аның белән идарә итү буенча чаралар күрүгә карап);<br>-нотариаль гамәл кылу турындагы үтенеч белән хокуктан файдалануга сәләтсез гражданин яисә кирәкле вәкаләтләре булмаган вәкил, тору урыны яки җирлектә яисә авыллар арасындагы территориядәге торак пунктта булуы буенча теркәлүе булмаган граждан мөрәҗәгать | Россия Юстиция министрлыгының 2017 елның 6 июнендәге 97 номерлы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | иткән;<br>-юридик зат исеменнән кылынган килешү аның низамнамәсендә яки нигезләмәсендә күрсәтелгән максатларына каршы килә;<br>-килешү Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми;<br>-нотариаль гамәл кылу өчен тапшырылган документлар Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми;<br>- нотариаль гамәл кылу өчен тапшырылган документларда бәян ителгән фактлар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган, ә раслауның шарты – Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә. | |

1.8) 4 номерлы кушымтада 2.10 пунктның 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җирле үзидарәнең вазифаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылганда физик һәм юридик затлар өчен дәүләт пошлинасын түләү буенча Россия Федерациясе Салым Кодексының 333.35 маддәсе 1 пунктының 11, 12 пунктчаларында, 333.38 маддәсендә билгеләнгән ташламалар бирелә”;

1.9) 5 номерлы кушымтада 2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр күздә тотылмый.<br>Кире кагу өчен нигезләр:<br>1) Мондый гамәл кылу законга каршы килә<br>2) гамәл башка җирлекнең яисә муниципаль районның җирле үзидарәсенең вазифаи заты тарафыннан яки нотариус тарафыннан кылынырга тиешле<br>(мирас мөлкәтен саклау буенча һәм кирәк булган очракта аның белән идарә итү буенча чаралар күрүгә карап);<br>3) нотариаль гамәл кылу турындагы үтенеч белән хокуктан файдалануга сәләтсез гражданин яисә | |

| | | |
|---|---|---|
| | киpəкле вəкaлəтлəpе булмaгaн вəкил, тору урыны яки жирлектə яисə авыллар арасындагы территориядəге торак пунктта булуы буенча теркəлүе булмаган граждан мөрəҗəгать иткəн;<br>4) Дəүлəт һəм муниципаль түлəүлəр турында Дəүлəт мəгълүмат системасы (алга таба – ДМС ДМТ) аша дəүлəт пошлинасын һəм нотариаль тарифны түлəү турында мəгълүмат килмəү;<br>5) Мөрəҗəгать итүче тарафыннан документлар тулы күлəмдə тапшырылмаган, йə гариза һəм (яки) документларда тулы булмаган һəм (яки) дөрес булмаган мəгълүмат бар.<br>6) нотариаль гамəллəр башкару өчен тапшырылган документлар Россия Федерациясе законнары талəплəренə туры килми;<br>7) нотариаль гамəллəр кылу өчен бирелгəн документларда бəян ителгəн фактлар, раслау Россия Федерациясе законнары нигезендə талəп ителгəн очракта, Россия Федерациясе законнарында билгелəнгəн тəртиптə расланмаган. | |

1.10) 7 кушымтада 2.5 пунктның 5 пунктчасын төшереп калдырырга, 6,7, пунктчаларын 5,6,7 пунктчалары дип санарга;

1.11) 1-7 кушымталарның 5.2 пунктын түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

Үзидарлек хезмəте күрсəтүче органнын, үзидарəлек хезмəте күрсəтүче органны урындагы затының, үзидарəлек хезмəткəренең карарлары һəм гамəллəренə (гамə кылмавына) шикаять почта белəн, күпфункцияле үзəк аша “Интернет” мəгълүмат телекоммуникация челтəрен, үзидарлек хезмəте күрсəтүче органның рəсми сайтын дəүлəт һəм үзидарəлек хезмəтлəренең Бердəм порталын яисə дəүлəт һəм үзидарəле хезмəтлəренең төбəк Бердəм порталын файдаланып җибəрелергə мөмкин, шулай у гариза бирүчене шəхсəн кабул итүдə кабул ителергə мөмкин.

Күпфункцияле үзəкнең, күпфункцияле үзəк хезмəткəренең карарларына һə гамəллəренə (гамəл кылмауларына) шикаять почта аша “Интернет” мəгълүмат телекоммуникация челтəрен, күпфункцияле үзəкнең рəсми сайтын, дəүлəт һə муниципаль хезмəтлəрнең бердəм порталын яисə дəүлəт һəм муниципал хезмəтлəрнең региональ порталын файдаланып җибəрелергə мөмкин, шулай у мөрəҗəгать итүченең шəхси кабул ителү вакытында кабул ителергə мөмкин.

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, әлеге оешмаларның рәсми сайтларын дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталын файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүченең шәхси кабул ителү вакытында кабул ителергә мөмкин.”;

1.12) 1-7 кушымталарның 5.1 пунктының 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны яки мәгълүматны баштагы кабул итүдәге кире кагуда юклыгы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә, 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсе 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан гайре, гариза бирүчедән таләп итү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирү шул очракта мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тиндәшле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән тәгаенләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән булса.”;

1.13) 1-7 кушымталарның 5.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга, муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 3 өлештә каралган оешмаларга яисә югарырак органга (ул булганда) кергән шикаять аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга карата гариза бирүчедән документларны кабул итүдә яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдә кире кагуына карата шикаять яисә андый төзәтүләр срогын бозуга карата шикаять очрагында – аны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә.”;

1.14) 1-7 кушымталарның 5.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.8. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле дип танылу очрагында Башкарма комитетка, КФҮ яисә 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларга муниципаль хезмәт күрсәткәндә беленгән бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында алар тарафыннан тормышка ашырылучы гамәлләр турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен кичерү сорала һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатларында гариза бирүчегә кылу зарур булган алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә”;

1.15) 1-7 нче кушымталарның 5.4 пункты 4 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

“Мөрәҗәгать итүче үзенең дәлилләрен раслый торган документларны (булган очракта) яисә аларның күчермәләрен тапшырырга мөмкин”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Рус Әшнәге авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Ру Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүма стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарста Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контроллек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге башлыгы В.Х.Хажие